КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 6 июнь г.Казань № 410

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпбалалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында» 1992 ел, 28 декабрь, 708 нче карарына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында» 1992 ел, 28 декабрь, 708 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1999 ел, 3 август, 476 нчы; 2004 ел, 17 декабрь, 540 нчы; 2007 ел, 6 декабрь, 693 нче; 2012 ел, 23 июнь, 545 нче; 2020 ел, 23 ноябрь, 1052 нче; 2022 ел, 11 март, 214 нче, 2022 ел, 6 февраль, 422 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«Күпбалалы гаилә составында фактта бергә яшәүче һәм 18 яшькә кадәрге һәм (яисә) 23 яшькә кадәрге балалары исәпкә алына, алар белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада көндезге бүлектә белем алган очракта, шул исәптән уллыкка (кызлыкка) алынган, үги кызы һәм үги улы булган балалар категорияләре, шулай ук, күпбалалы гаилә әгъзаларының барысы да Россия Федерациясе гражданнары булу шарты белән, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмада ата-аналардан аерым яшәүче балалар категорияләре исәпкә алына.».

Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры А.В.Песошин